**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**16.11.2023 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яштәге гражданнардан (80 яштән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, № 647 указы буенча мобилизациялэнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Яңа Минзәләбаш авылы халкының күпләп ял итү урынын төзү, ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эскәмияләр ясау, милли спорт төрләре өчен спорт җиһазлары урнаштыру, стойка ясау һәм баннер сатып алу, сәхнә һәм трибуна ясау, территорияне электрлаштыру);

2) Яңа Минзәләбаш урамындагы Яңа Минзәләбаш торак пунктында ИДН (ясалма юл тигезсезлеге) (килешү буенча эш өчен түләү) әзерләү;

3) Яңа Минзәләбаш урамындагы Яңа Минзәләбаш торак пунктында терәкләр белән өстәмә яктырту нокталары урнаштыру (килешү буенча эшләрне сатып алу, урнаштыру, түләү);

4) Яңа Минзәләбаш торак пунктында 2 данә янгын гидрантын сатып алу, урнаштыру һәм тоту (килешү буенча эш өчен түләү);

5) Яңа Минзәләбаш урамындагы Яңа Минзәләбаш торак пунктында Минзәлә елгасының яр буе зонасын чистарту.

3. Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
МБ башлыгы Р.Ә. Каримов